**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль район Советы

КАРАРЫ

“28” нче декабрь 2018 нче ел № 44-259

“Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль район Советының 2017 нче елның 30 нчы октябрендәге 30-175 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәт турында” Нигезләмәгә өстәмәләр кертү хакында”

2018 нче елның 3 нче августындагы “Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе кануннары үтәлешен контрольдә тотуны камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым канун актларына үзгәрешләр кертү хакында” 307-ФЗ номерлы Федераль канунның 11 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль район Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль район Советының 2017 нче елның 30 нчы октябрендәге 30-175 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәт турында” Нигезләмәнең 9 пунктын 9.4, 9.5, 9.5.1, 9.6 пунктчалары белән тулыландырырга:

“9.4. Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе гражданның хезмәт килешүе шартларында оешмада һәм (яисә) әлеге оешмада эшләрне башкаруга (әлеге оешмада хезмәт күрсәтү) ризалык бирү турында язмача мөрәҗәгатен карарга тиеш, әгәр әлеге оешма белән идарә итүнең аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына керсә, шулай ук гражданга кабул ителгән карар турында хәбәр итәргә тиеш.”;

“ 9.5. Муниципаль вазыйфаларны биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы затлар түбәндәгеләргә хокуклы түгел:

1) коммерция оешмасы яки коммерцияле булмаган оешма идарәсендә катнашырга, түбәндәге очраклардан тыш:

а) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр советы идарәсендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, сәяси партиядә катнашу, съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешма, торак, торак – төзелеш, гараж кооперативлары, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларының гомуми җыелышында, күчемсез милек милекчеләр ипташлегендә катнашу;

б) Россия Федерациясе Президенты яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез нигездә катнашу;

в) Россия Федерациясе яисә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең норматив актлары яисә Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә Федераль милектә яки Татарстан Республикасы милкендә булган оешмалар яисә идарәне гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында Россия Федерациясе яисә Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрен (устав капиталында катнашу өлешләре) түләүсез нигездә күрсәтү;

г) муниципаль берәмлек идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль милектә булган оешмалар яисә идарә итүне гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актларга туры китерү (устав капиталында катнашу өлешләре);

д) федераль кануннар белән каралган башка очракларда.";

"9.5.1. шәхсән яки вәкаләтле затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә.";

"9.6. Җитәкче булган муниципаль хезмәткәр җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында мәнфәгатьләр конфликтын бетерү максатларында әлеге җирле үзидарә органының сайлау профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен әлеге вазыйфаны биләгән чорда яклый алмый.".

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында" "Интернет" мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә htt://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль
районы Башлыгы

Козлов В.М.